**КАРАР Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге составына керүче Кодаш авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2024 елның 09 ноябре № 2

Кодаш авылы, авыл мәдәният йорты

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10. №131-ФЗ Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28.07. №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Кодаш авылы» муниципаль берәмлеге составына керүче Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Кодаш авылы торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

карар кылды:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кодаш авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган гражданнардан, өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган баласы булган күпбалалы гаиләләрдән , хезмәттәге хәрби хезмәткәрләрдән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, 500,00 сум күләмендә гражданнарга үзара салым кертергә.

2.Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Совет урамыннан Кудаш авылының Пионер урамына кадәр юл салу (ЩПС сатып алу һәм ташу));
- Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Кудаш авылының су җыю манарасына артезиан төяү насосы һәм өстәмә җайланмалар сатып алу).

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Муниципаль берәмлек башлыгы**
**«Кодаш авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлек башлыгы Г. Ә. Хәйсарова**